**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№ 5173**
**08.10.2020**

Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамәнең һәм территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогын арендалау шартнамәсенең үрнәк формаларын раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 22 статьясы, 39.6 статьясының 2 пунктының 5 пунктчасы, 39.8 статьясының 6, 7, 8 пунктлары, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46.4 статьясы, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамәнең үрнәк формасын (стандарт торак төзү максатында территорияне комплекслы үзләштерүдән тыш) 1 нче кушымтада каралганча;

2) территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогын арендалау шартнамәсенең үрнәк формасын 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 8 октябрендәге
5173 номерлы карарына
1 нче кушымта

Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә №________

Яр Чаллы шәһәре «___»________20___ ел

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе _______________________ нигезендә эш итүче
(документның исеме)
_______________________________________ исеменнән, алга таба «Вәкаләтле орган» дип
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
аталучы, бер яктан һәм ___________________________________________ нигезендә эш итүче
(документның исеме)
______________________________________________ исеменнән, алга таба «Төзүче» дип
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
аталучы, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар, аукцион нәтиҗәләре (№_____ лот буенча ___________ №_______ территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогын арендалау шартнамәсе төзү хокукына _____________ беркетмә) нигезендә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 46.4 статьясына туры китереп, түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне төзеделәр:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Әлеге шартнамә буенча Төзүче шартнамәдә билгеләнгән срокта үз көче белән һәм үз хисабына һәм (яки) башка затларны һәм (яки) башка затларның акчаларын җәлеп итеп, территорияне комплекслы үзләштерү буенча әлеге шартнамәнең 2.2.1-2.2.3, 2.3.3, 2.3.4 пунктларында каралган йөкләмәләрне үтәргә йөкләмә ала, ә Вәкаләтле орган әлеге йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле шартлар тудырырга йөкләмә ала.

1.2. Территорияне комплексы үзләштерү түбәндәгеләрне үз эченә ала:
- территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү;
- әлеге территория чикләрендә җир участоклары булдыру;
- әлеге территория чикләрендәге җир участокларында транспорт, коммуналь һәм социаль инфраструктура объектлары, шулай ук территорияне планлаштыру документлары нигезендә башка объектлар төзү.

1.3. Территорияне комплексы үзләштерү Төзүчегә арендага бирелгән җир участогы чикләрендә яки әлеге җир участогыннан булдырылган җир участоклары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.4. Комплексы үзләштерелергә тиешле территорияне тәшкил итүче җир участогы турында мәгълүматлар:
- кадастр номеры __________________;
- мәйданы ___________________________;
- җирләр категориясе ____________________;
- рөхсәт ителгән файдалану _________________________________________;
- файдалануда чикләүләр һәм хокукка чикләүләр _____________________;
- урнашу урыны _____________________________________________________.

## 2. Якларның йөкләмәләре

2.1. Вәкаләтле орган йөкләмә ала:

2.1.1. Территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын карап тикшерүне һәм раслауны ________________ кадәр срокта тәэмин итәргә.
(максималь срок)

2.1.2. Яр Чаллы шәһәренең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программасы нигезендә, әлеге шартнамәнең 1.4 пунктында күрсәтелгән җир участогы чикләрендә коммуналь инфраструктура объектларын (әлеге җир участогы чигендә әлеге җир участогында төзелгән коммуналь инфраструктура объектларына тоташтыруны (технологик тоташтыруны) тәэмин итү өчен кирәкле) төзүне һәм (яки) реконструкцияләүне ________________ кадәр срокта тәэмин итәргә.
(максималь срок)

2.2. Төзүче йөкләмә ала:

2.2.1. Территориаль планлаштыру документлары, Яр Чаллы шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, шул исәптән территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең хисап күрсәткечләре һәм күрсәтелгән объектларның халык өчен территориаль мөмкинлегенең максималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең хисап күрсәткечләре нигезендә, территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын ________________ кадәр срокта әзерләргә һәм Вәкаләтле органга тапшырырга.
(максималь срок)

2.2.2. Әлеге шартнамәнең 1.4 пунктында күрсәтелгән җир участогында яки әлеге җир участогыннан булдырылган җир участокларында төзекләндерү, шул исәптән яшелләндерү буенча әлеге шартнамәдә каралган чараларны ____________ кадәр срокта гамәлгә ашырырга.
(максималь срок)

2.2.3. Территорияне межалауның расланган проекты нигезендә, әлеге шартнамәнең 1.4 пунктында күрсәтелгән җир участогыннан җир участоклары булдыруны гамәлгә ашырырга.

2.2.4. Төзелеше төзүче акчалары хисабына гамәлгә ашырылган коммуналь, транспорт һәм социаль инфраструктура объектларына милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә һәм түләүсез тапшыру шартларында әлеге объектларны муниципаль милеккә тапшырырга.

2.2.5. Территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә, әлеге шартнамәнең 2.3.4 пунктында күрсәтелгән объектлар белән беррәттән капиталь төзелеш объектларын төзүне ________________ кадәр срокта гамәлгә ашырырга.
(максималь срок)

2.3. Яклар йөкләмә ала:

2.3.1. Әлеге шартнамәне төзү белән бер үк вакытта әлеге шартнамәнең 1.4 пунктында күрсәтелгән җир участогын арендалау шартнамәсе дә төзергә.

2.3.2. Территорияне планлаштыру буенча документлар расланган көннән башлап өч ай эчендә, тиешле эшләрнең башлану һәм тәмамлану срокларын күрсәтеп, һәр чарага карата территорияне үзләштерү (шул исәптән капиталь төзелеш объектларын төзү һәм файдалануга тапшыру) чараларын гамәлгә ашыру графигын үз эченә алган әлеге шартнамәгә өстәмә килешү төзергә.

2.3.3. Һәр чараны гамәлгә ашыру графигы нигезендә, күрсәтелгән графикларда каралган срокларда, капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруны да кертеп, территорияне үзләштерү буенча чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

2.3.4. Территорияне планлаштыру проекты нигезендә, әлеге шартнамәнең 1.4 пунктында күрсәтелгән җир участогында яки әлеге җир участогыннан булдырылган җир участокларында коммуналь, транспорт һәм социаль инфраструктура объектларын төзүне _____________________ кадәр срокта гамәлгә ашырырга.
(максималь срок)

## 3. Якларның җаваплылыгы

3.1. Әлеге шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплы.

## 4. Шартнамәнең срогы

4.1. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы ___________________________________ тәшкил итә.

## 5. Шартнамәне үзгәртү, туктату, өзү

5.1. Әлеге шартнамәгә теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр, әгәр алар язма рәвештә башкарылган һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган булса, гамәлдә була. Шул ук вакытта әлеге шартнамәгә кертелә торган теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр аның аерылгысыз өлеше булып тора.

5.2. Аны бүлү сәбәпле, әлеге шартнамәнең 1.4 пунктында күрсәтелгән җир участогының гамәлдә булуы тукталу яки әлеге җир участогыннан булдырылган җир участокларына өченче затларның хокуклары барлыкка килү әлеге шартнамәдә билгеләнгән хокукларны һәм бурычларны туктату өчен нигез булып тормый.

5.3. Әлеге шартнамә граждан законнарында каралган нигезләр буенча, бары тик суд карары буенча гына өзелергә мөмкин.

## 6. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

6.1. Әлеге шартнамәне үтәгәндә килеп чыгарга мөмкин булган бәхәсләр һәм каршылыклар, мөмкин булганча Яклар арасындагы сөйләшүләр юлы белән хәл ителәчәк.

6.2. Яклар килешмәгән очракта, бәхәсләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә суд тәртибендә хәл ителә.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Әлеге шартнамә бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә – Якларның һәркайсы өчен бер нөсхәдә төзелде.

7.2. Шартнамә имзаланган вакыттан үз көченә керә һәм Яклар тарафыннан әлеге шартнамә буенча үз йөкләмәләре тулысынча үтәлгәнгә кадәр, әмма әлеге шартнамәнең 4.1 пунктында күрсәтелгәннән артмаган срокта гамәлдә була.

7.3. Әлеге шартнамәдә каралмаган барлык очракларда Яклар гамәлдәге законнарга, муниципаль хокукый актларга таяна.

## 9. Якларның реквизитлары һәм имзалары

Вәкаләтле орган　　　　　　　　　　　　　　　　Төзүче

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы　　　　　　Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2020 елның 8 сентябрендәге
5173 номерлы карарына
2 нче кушымта

Территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогын
арендалау шартнамәсе №________

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе ______________________________ нигезендә
(документның исеме)
эш итүче ______________________________________________ исеменнән, алга таба
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
«Арендага бирүче» дип аталучы, бер яктан һәм ______________________________ нигезендә
(документның исеме)
эш итүче ______________________________________________________ исеменнән,
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
алга таба «Арендатор» дип аталучы, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 46.4 статьясына туры китереп,
*№_____ лот буенча аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерү буенча ____________ елның «____» ____________ №_______ беркетмә нигезендә,[1]
*№_____ лот буенча аукцион нәтиҗәләре турында _____ елның «____» __________ №_______ беркетмә нигезендә [2]
түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне (алга таба – Шартнамә) төзеделәр:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре __________________________ ______________________________________________________________________ адресы буенча урнашкан, мәйданы ___________ кв.м. __________________________________ кв.м.,
(сүзләр белән)
кадастр номеры _____________________________ булган җир участогын (алга таба – җир участогы) Арендага бирүче бирә, ә Арендатор кабул итә һәм аредалау шартларында файдалана.

1.2. Җир участогы торак пунктлар җирләренә керә.

1.3. Җир участогының рөхсәт ителгән файдалану төре: __________________________

Җир участогының күрсәтелгән рөхсәт ителгән файдалану төре ахыргы булып тора һәм үзгәртелергә тиеш түгел.

1.4. Җир участогы йөкләмәләр (сервитут) белән _________________________________.
(чикләнгән яисә чикләнмәгән)

## 2. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы

2.1. Шартнамә _______________________ кадәр срокка төзелде.[3]
(аренда срогы)

---

[1] Әлеге абзац аукцион үткәрелмәде дип танылган очракта кертелә
[2] Әлеге абзац аукцион җиңүчесе белән шартнамә төзелгән очракта кертелә
[3] Срок РФ Җир кодексының 39.8 статьясының 8 пунктының 4 пунктчасы нигезендә билгеләнә

2.2. Шартнамә срогын исәпли башлау Арендатор тарафыннан шартнамә һәм кабул итү-тапшыру акты имзаланган датадан башлап башкарыла.

2.3. Шартнамә Шартнамәнең 2.1, 2.2 пунктларында каралган шартларда төзелгән дип санала һәм мәҗбүри дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

2.4. Шартнамә Шартнамәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән датадан соң килә торган көннән гамәлдә булуын туктата. Шул ук вакытта Арендатор җир участогын кире кайтарырга тиеш, ә Арендага бирүче Шартнамәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән датадан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, кабул итү-тапшыру акты буенча кабул итәргә тиеш.

## 3. Беренче аренда түләвен кертү тәртибе

3.1.* Шартнамә буенча беренче аренда түләвенең күләме аукцион предметының башлангыч бәясенә тигез күләмдә билгеләнгән һәм _________ (_________________________) сум тәшкил итә.[4]

3.1.* Шартнамә буенча беренче аренда түләвенең күләме аукцион нәтиҗәләре буенча билгеләнгән һәм ____________(_____________________________________) сум тәшкил итә. [5]

3.2. Кертелгән задаток суммасы ___________ (________________________________) сум күләмендә Шартнамә төзү хокукы өчен түләү хисабына исәпләнде.

3.3. Беренче аренда түләве (задаток суммасыннан тыш) _____________ (___________________________________________) сум күләмендә Арендатор тарафыннан Шартнамә имзалаган вакыттан башлап 10 көн эчендә түләнә.

3.4. Беренче аренда түләве арендалауның беренче ае өчен түләү булып тора.

3.5. Шартнамә вакытыннан алда өзелгән очракта, Шартнамә өзелгән вакытка кадәр Арендатор тарафыннан түләнгән Шартнамәнең 3.1. пунктында күрсәтелгән акчалар Арендаторга кире кайтарылмый.

## 4. Шартнамә буенча аренда түләве

4.1. Шартнамә төзү вакытына җир участогы өчен еллык аренда түләвенең күләме _____________________________ (_____________________________________________) сум тәшкил итә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән еллык аренда түләвенең күләме яклар тарафыннан килештерелгән һәм аренда түләве күләмен билгеләү турында килешүдә билгеләнгән.

4.2. Аренданың икенче аеннан Арендатор 4.1 пунктта күрсәтелгән аренда түләвен, хисап аеннан соң килүче айның 15 числосына кадәр ай саен тигез өлешләрдә, Аренда түләве күләмен билгеләү турында Арендатор тарафыннан расланган Килешүдә күрсәтелгән счетка күчерә.

4.3. Шартнамә буенча еллык аренда түләвенең күләме билгеләнмәгән һәм Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, шул исәптән закон үзгәргән, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан аренда түләвенең башка ставкалары һәм/яки аренда түләве ставкаларына коэффициентлар (шул исәптән индексация коэффициентлары) кертелгән очракта, Арендатор белән килешмичә, Арендага бирүче тарафыннан үзгәртелергә мөмкин. Аренда түләве Арендатор тарафыннан мәҗбүри түләнергә тиеш.

4.4. Объектив сәбәплүрдән тыш Арендатор тарафыннан җир участогыннан файдаланмау, Арендаторны Шартнамә буенча аренда түләвен кертүдән азат итү өчен нигез булып тормый.

---

[4] Әлеге абзац аукцион үткәрелмәде дип танылган очракта кертелә

[5] Әлеге абзац аукцион җиңүчесе белән шартнамә төзелгән очракта кертелә

## 5. Арендаторның хокуклары һәм бурычлары

5.1. Арендатор хокуклы:

5.1.1. Шартнамәдә билгеләнгән шартларда җир участогыннан файдаланырга;

5.1.2. төзелеш өчен рөхсәт нигезендә биналар һәм корылмалар төзергә;

5.1.3. җир участогыннан файдалануга гамәлдәге законнарда каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

5.2. Арендатор бурычлы:

5.2.1. Территорияне комплекслы үзләштерү турында 20___ елның __________ №____ шартнамәнең һәм Шартнамәнең барлык шартларын тулы күләмдә үтәргә.

5.2.2. җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалануның билгеләнгән төре нигезендә файдаланырга;

5.2.3. гамәлдәге законнар нигезендә җир участогында билгеләнгән межалау, геодезия һәм башка махсус билгеләрне сакларга;

5.2.4. җир участогын саклау буенча чараларны гамәлгә ашырырга;

5.2.5. җир участогын үзләштерүгә үз вакытында керешергә;

5.2.6. Шартнамәдә, аренда түләве күләмен билгеләү турында Килешүдә билгеләнгән күләмдә, тәртиптә һәм срокларда аренда түләвен үз вакытында һәм тулы күләмдә кертергә;

5.2.7. җир участогыннан файдаланганда шәһәр төзелеше регламентлары, төзелеш, экология, санитария-гигиена, янгынга каршы һәм башка кагыйдәләр, нормативлар таләпләрен үтәргә;

5.2.8. җир эшләрен һәм территорияне төзекләндерү эшләрен үткәргәндә инженерлык коммуникацияләренең куркынычсызлыгын тәэмин итәргә;

5.2.9. җир участогындагы эшләрне үткәрү өчен вәкаләтле органнарның таләп итelә торган тиешле рөхсәтләрен алмыйча, аларны гамәлгә ашырмаска;

5.2.10. җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне үткәргәндә, гамәлдәге законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә җир участогын рекультивацияләү эшләрен үткәрергә;

5.2.11. Арендага бирүченең таләбе буенча биш көн срокта аренда түләве турында түләү документларын, гамәлгә кую документларын, җир участогыннан файдалану буенча Арендатор эшчәнлегенә турыдан-туры мөнәсәбәте булган Шартнамә шартлары аның тарафыннан үтәлүгә кагылышлы мәсьәләләрне ачыклау өчен, башка документларны тапшырырга;

5.2.12. Арендага бирүче тарафыннан җибәрелә торган хатларны һәм башка корреспонденцияне алуны тәэмин итәргә;

5.2.13. өч эш көне эчендә язма рәвештә Арендага бирүчегә реквизитлар: исеме, урнашу урыны, почта адресы, теркәлү урыны, түләү һәм башка реквизитлар үзгәрү турында хәбәр итәргә. Арендатор тарафыннан әлеге шартлар үтәлмәгән очракта, Шартнамәдә күрсәтелгән адрес буенча Арендага бирүче тарафыннан җибәрелгән хатлар һәм башка корреспонденция Арендаторга җибәрелгән дип санала, ә Арендатор тиешле хатларны, корреспонденцияне алган, аңа хәбәр ителгән дип таныла;

5.2.14. Арендатор тарафыннан Шартнамә шартлары, шулай ук гамәлдәге законнар нормалары үтәлешен тикшерү өчен, Арендага бирүченең вәкилләренә һәм җирләрдән файдалануга һәм аларны саклауга дәүләт контроле органнарына җир участогына тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә.

Җир участогында тиешле хезмәтләр тарафыннан авария-ремонт һәм башка шундый эшләр үткәрү кирәк булганда, аларга тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә;

5.2.15. Шартнамә имзаланган датадан башлап 30 календарь көн эчендә, көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару (Арендатор тарафыннан җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килә торган эшчәнлек гамәлгә ашырылган очракта, шулай ук мондый калдыкларны да чыгару) өчен тиешле хезмәтләрне күрсәтүче оешма белән шартнамә төзергә;

5.2.16. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы тәмамлануга бәйле рәвештә дә, аны вакытыннан алда азат иткәндә дә җир участогын азат итү турында Арендага бирүчегә язмача хәбәр итәргә;

5.2.17. хокукларны бирмәскә һәм Шартнамә нигезендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча бурычны күчерүне гамәлгә ашырмаска;

5.2.18. җир учстогында урнашкан һәм Арендатор карамагындагы биналарны, каралтыларны, корылмаларны, төзелеше тәмамланмаган объектларны, аларның өлешләрен яки әлеге объектларга хокуктагы өлешләрне тартып алмаска;

5.2.19. түбәндәгеләр өчен җир участогыннан файдаланмаска:

- Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән товарлар сату, мондый рөхсәтне (лицензияне) бирүгә вәкаләтле органның махсус рөхсәте (лицензиясе) нигезендә әйләнештә чикләнгән товарларны сату очракларыннан тыш;

- составында психотроп яисә наркотик матдәләр һәм (яки) аларның прекурсорлары булырга мөмкин булган товарларны сату, мондый рөхсәтне (лицензияне) бирүгә вәкаләтле органның махсус рөхсәте (лицензиясе) нигезендә мондый товарларны сату очракларыннан тыш;

- азартлы уеннар оештыруга һәм (яки) үткәрүгә бәйле эшчәнлекне, шул исәптән Интернет челтәре аша азартлы уеннар оештыру һәм (яки) үткәрү буенча өченче затлар эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

Арендаторның әлеге пунктчада каралган бурычларын яклар Шартнамәнең әһәмиятле шартлары дип таныйлар;

5.2.20. чиктәш җир участокларының хокукка ия затларының, сервитут хуҗаларының хокукларын бозмаска;

5.2.21. җир участогы тулысынча яисә өлешчә линия объектына карата билгеләнгән сак зонасында урнашкан очракта, аның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, линия объектының хуҗасы вәкилләренең һәм линия объектын эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешма вәкилләренең әлеге объектка ирекле керүен тәэмин итәргә;

5.2.22. җир участогы гомуми файдаланудагы су объектының яр буе полосасы чикләрендә урнашкан очракта, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектына һәм аның яр полосасына ирекле керүен тәэмин итәргә;

5.2.23. Шартнамәнең 2.4 пунктында билгеләнгән срок эчендә, җир участогын Шартнамә төзелгән вакытка кадәр булган элекке хәленнән һәм сыйфатыннан начар булмаган хәлдә һәм сыйфатта кабул итү-тапшыру акты буенча Арендага бирүчегә кире кайтарырга;

5.2.24. Арендага бирүче тарафыннан Шартнамә проекты җибәрелгән көннән башлап 30 көн эчендә, имзаланган нөсхәләрне һәм хокукларны теркәү өчен кирәкле, аңа теркәлгән документларны Арендага бирүчегә тапшырырга.

5.3. Яклар, территорияне комплексны үзләштерү турында 20___ елның __________ №____ шартнамә шартлары нигезендә, күрсәтелгән графикларда каралган срокларда һәр чараны гамәлгә ашыру графикларына туры китереп, капиталь төзелеш объектларын төзүне һәм файдалануга тапшыруны да кертеп, территорияне үзләштерү буенча чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә йөкләмә алалар.

## 6. Арендага бирүченең хокуклары һәм бурычлары

6.1. Арендага бирүче:

6.1.1. Арендатор тарафыннан җир участогыннан файдалануны контрольдә тоту;

6.1.2. Арендатор тарафыннан Шартнамәнең яклар тарафыннан мөһим дип танылган шартлары бозылган очракта, Шартнамәне үтәүдән берьяклы тәртиптә баш тартырга:

- Арендатор тарафыннан Шартнамәнең 3.3 пунктында күрсәтелгән күләмдә һәм срокларда беренче аренда түләве кертелмәү;

- Шартнамәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән тәртиптә, Арендатор тарафыннан аренда түләве Шартнамәдә билгеләнгән түләү срогы чыккач, рәттән икедән артык тапкыр кертелмәү;

- Арендатор тарафыннан җир участогыннан аның максатчан билгеләнешенә туры килмәгәнчә файдалану;

- Арендатор тарафыннан җир участогыннан экологик хәлнең начарлануына китерә торган ысуллар белән файдалану;

- законда һәм (яки) проект документларында билгеләнгән сроклар эчендә җир участогыннан файдаланмау (үзләштермәү);

- Шартнамәнең 5.2.2, 5.2.17 һәм (яки) 5.2.19 пунктларында каралган бурычларны үтәмәгәндә;

- Шартнамә төзелгән көннән башлап өч ел үткәннән соң, төзелеше Шартнамәдә каралган күчемсез милек объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт булмау;

- гамәлдәге законнарда каралган башка нигезләр буенча.

Шул ук вакытта Шартнамә Арендатор тарафыннан мондый баш тарту турында язмача хәбәр алынганнан соң 30 календарь көн узгач өзелергә тиеш;

6.1.3. Шартнамә буенча Арендатор тарафыннан йөкләмәләр үтәлмәгән очракта, суд тәртибендә аның мөлкәтенә һәм мөлкәт хокукларына түләтүне мәҗбүр итәргә;

6.1.4. Арендатор тарафыннан хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җирләрнең торышы һәм экологик хәл начарлану сәбәпле килгән зыянны түләтүгә;

6.1.5. Шартнамәдә каралган неустойканы түләүне таләп итәргә;

6.1.6. Арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү сроклары (түләүнең бер срогыннан артык) бозылган очракта, Арендага бирүче үз теләге белән, Арендага бирүче тарафыннан билгеләнгән срокка аренда түләвен срогыннан алда кертүне таләп итәргә хокуклы, әмма бердән артмаган срокка;

6.1.7. Арендатор тарафыннан Шартнамә шартлары, гамәлдәге законнар, шулай ук муниципаль хокукый актлар үтәлү предметына карау максатында, җир участогы территориясенә тоткарлыксыз керү;

6.1.8. гамәлдәге законнарда каралган башка хокукларны тормышка ашырырга.

6.2. Арендага бирүче бурычлы:

6.2.1. Шартнамә шартларын тиешенчә үтәргә;

6.2.2. кабул итү-тапшыру акты нигезендә җир участогын Арендаторга тапшырырга;

6.2.3. әгәр ул Шартнамә шартларына, гамәлдәге законнарга, муниципаль хокукый актларга каршы килмәсә, әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китермәсә һәм башка затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмаса, Арендаторның хуҗалык эшчәнлегенә тыкшынмаска;

6.2.4. Шартнамәнең 2.4 пунктында билгеләнгән срок эчендә, кабул итү-тапшыру акты буенча җир участогын кабул итәргә;

6.2.5. Арендатор тарафыннан Шартнамә имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соң булмаган срокта, хокук(-лар)ны дәүләт теркәве турында гаризаны һәм күчемсез мөлкәт объектына карата аңа теркәлә торган документларны хокукларны теркәү органына җибәрергә.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Шартнамәдә күрсәтелгән бурычлар яклар тарафыннан үтәлмәгән яки тиешенчә үтәлмәгән очракта, яклар законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

7.2. Арендатор, Шартнамә шартларында, ягъни 5.2 пунктта (Шартнамәнең 5.2.6 пунктчасыннан тыш) каралган йөкләмәләрне үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) очракта, Арендага бирүчегә Шартнамәнең 4.1 пунктында каралган еллык аренда түләве күләменнән 10% күләмендә неустойка (штраф) түләргә йөкләмә ала.

7.3. Арендатор тарафыннан Шартнамәнең 4.2 пункты бозылган очракта, срогы

чыккан һәр көн өчен аренда түләүләре суммасыннан 0,1% күләмендә пенялар исәпләнә.

7.4. Арендатор тарафыннан Шартнамәнең 2.4 пункты бозылган очракта, Арендатор җир участогын кире кайтаруның срогы чыккан барлык вакыт өчен нигезсез баю суммасын түләргә, шулай ук җир участогын кире кайтаруның срогы чыккан һәр көн өчен нигезсез баю суммасыннан 0,1% күләмендә неустойка (пеня) һәм җир учатогын тиеш хәлдә кайтармау нәтиҗәсендә килгән зыянны түләргә тиеш.

7.5. Шартнамә шартларын бозу ачыкланган очракта, Шартнамәнең ягы гаепле якка бозу фактын бәян итеп, язмача хәбәр җибәрергә тиеш.

## 8. Шартнамәне өзү

8.1. Арендаторны үзгәртеп корган очракта, Арендаторның хокуклы варисы, яңа реквизитларны күрсәтеп, Арендага бирүчегә хокук күчемлеге турында хәбәр итәргә тиеш. Арендатор юкка чыгарылган очракта, Шартнамә, өченче затларга хокуклар һәм бурычлар күчмичә, өзелергә тиеш.

8.2. Түбәндәге очракларда Шартнамә Арендага бирүче тарафыннан өзелә:

- 20___ елның _________ №_____ территорияне комплексלы үзләштерү шартнамәсен өзү;

- Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән җир участогыннан яңа җир участоклары булдыру;

- 20___ елның _________ №_____ территорияне комплекслы үзләштерү шартнамәсендә күрсәтелгән территорияне комплекслы үзләштерү графигын бозу;

- Россия Федерациясе Җир кодексының 46 статьясында каралган очракларда;

- Арендатор тарафыннан аренда түләве кертелмәү һәм аренда түләве буенча бурычлар барлыкка килү, ике ай өчен аренда түләвеннән артып киткән суммадан артык неустойка исәпләнү;

- Шартнамә шартларында, ягъни Шартнамәнең 5.2 пунктының 5.2.2, 5.2.17, 5.2.19 пунктчаларында каралган башка йөкләмәләр Арендатор тарафыннан үтәлмәү яки тиешенчә үтәлмәү;

- законнарда каралган башка очракларда.

## 9. Башка шартлар

9.1. Шартнамәдә җайга салынмаган мәсьәләләр гамәлдәге законнар, муниципаль хокукый актлар белән җайга салына.

9.2. Шартнамәне үтәгәндә барлыкка килә торган бәхәсләр Татарстан Республикасы Арбитраж суды тарафыннан аларның компетенциясе нигезендә карала.

9.3. Аукционның аукцион предметы булып торучы җир участогын арендалау шартнамәсен төзүдән качарга тырышкан җиңүчеләре турында һәм күрсәтелгән шартнамәләр Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясындагы 13, 14 яки 20 пунктлары нигезендә төзелә торган һәм аларны төзүдән качкан башка затлар турында мәгълүматлар аукционның намуссыз катнашучылары реестрына кертелә.

9.3. Шартнамә ________ биттә төзелде һәм бертигез юридик көчкә ия өч нөсхәдә
(сүз белән)

имзаланды, түбәндәгеләргә бирелде:

- Арендага бирүче - 1 нөсхә;

- Арендатор - 1 нөсхә;

- хокукларны теркәү органы - 1 нөсхә.

## 10. Шартнамәгә кушымталар

10.1. Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора:

- җир участогын кабул итү-тапшыру акты.

10.2. Шартнамәгә кушымта булып тора:

- аренда түләве күләмен билгеләү турында килешү;

- _____ елның ________ №___ территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә күчермәсе.

Якларның реквизитлары:

| | |
|---|---|
| Арендага бирүче: | Арендатор: |
| «Татарстан Республикасы<br>Яр Чаллы шәһәре<br>муниципаль берәмлеге<br>Башкарма комитеты» МКУ<br>адресы: Татарстан Республикасы,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Х. Туфан проспекты, 23 йорт. | ИНН ОГРН<br>тел.<br>факс ___________________________ |

Якларның имзалары:

| | |
|---|---|
| Арендага бирүче: | Арендатор: |
| ________________________________________<br>М.У. | ________________________________<br>М.У. (булган очракта) |

ҖИР УЧАСТОГЫН

КАБУЛ ИТҮ-ТАПШЫРУ

АКТЫ

Яр Чаллы шәһәре «_____»_____________20___ ел

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, _______________________ нигезендә эш итүче
(документның исеме)
_____________________________________________________________________ исеменнән,
алга таба «Арендага бирүче» дип аталучы, мәйданы __________ кв.м., кадастр номеры _____________________, рөхсәт ителгән файдалану төре ____________________________
булган, ____________________________________ адресы буенча урнашкан җир участогын тапшыра, ә __________________________________________________________,
(юридик затның исеме)

___________________ нигезендә эш итүче ________________________________ исеменнән,
(документның исеме) (вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
алга таба «Арендатор» дип аталучы кабул итә.

Җир участогы торак пунктлар җирләренә карый.

Кабул итү-тапшыру актын имзалаган вакытка яклар җир участогы торышына һәм аның характеристикаларына претензия белдермиләр.

Якларның имзалары

«Арендага бирүче»:

«Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ
адресы: Татарстан Республикасы,
Яр Чаллы шәһәре,
Х. Туфан проспекты, 23 йорт.

_____________________________
М.У.

«Арендатор»:

ИНН
ОГРН
тел.

_____________________________
М.У. (булган очракта)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идәрәсе башлыгы Н.И. Галиева